**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 март № 177

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле эшчәнлек тармакларында дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм әлеге тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәләлеге турында докладлар әзерләү хакында» 2011 ел, 13 август, 676 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле эшчәнлек тармакларында дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген), муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм әлеге тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәләлеге турында докладлар әзерләү хакында» 2011 ел, 13 август, 676 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 ноябрь, 911 нче, 2015 ел, 02 февраль, 50 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:
дүртенче абзацта «кәгазьдә» сүзләрен төшереп калдырырга;
бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;
2 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;
түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$. Эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәләлеге хакында докладларга кертелгән мәгълүматлар, шулай ук эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең нәтиҗәләлеге хакында докладлар дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында федераль статистик күзәтү формаларындагы мәгълүматларга туры килергә тиеш.»;

4 пунктта:

бишенче һәм алтынчы абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә федераль дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында докладлар федераль дәүләт хакимияте органнары билгеләгән срокларда тиешле федераль дәүләт хакимияте органнарына җибәрелә;»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән килештерелгән һәм җитәкчеләр имзалаган төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең нәтиҗәлелеге хакында докладларны электрон рәвештә «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба – «Идарә» ДАС) аша урнаштырырга;»;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында статистик мәгълүматларны электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша урнаштырырга;»;

ундүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә федераль дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында статистик мәгълүматларны электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша урнаштырырга;»;

унбишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен, хисап елыннан соң килә торган айның 15 мартына кадәр төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге хакында, муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең нәтиҗәлелеге хакында җыелма докладлар әзерләүне гамәлгә ашырырга, эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең (күзәтчелекнең) нәтиҗәлелеге хакында килештерелгән докладларны, шулай ук эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең нәтиҗәлелеге хакында докладларны электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша урнаштырырга;»;

бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «электрон рәвештә «Мониторинг» мәгълүмат системасында» сүзләрен «электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта:

икенче абзацта «электрон рәвештә «Мониторинг» мәгълүмат системасында» сүзләрен «электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктта:

җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм Татарстан Республикасы

Икътисад министрлыгы белән килештерелгән һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары җитәкчеләре имза куйган муниципаль тикшерүне гамәлгә ашыру турында һәм мондый тикшерүнең нәтиҗәлелеге хакында докладларны электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша урнаштырырга;»;

уникенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«статистик мәгълүматларны электрон рәвештә «Идарә» ДАС аша урнаштырырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков